| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.02.2021 г.Казань № 43

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте турында» федераль законы, 2005 елның 1 февралендә кул куелган 112 номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә бәйге турында» Россия Федерациясе Президенты Указы, 2018 елның 31 мартында кабул ителгән 397 номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә бәйле бәйге үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә

**боерам:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 19 мартында кул куелган 80 номерлы «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында Нигезләмәсен раслау турында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктның «г» подпунктындагы икенче һәм өченче абзацларында «эш (хезмәт) урыны буенча» сүзләрен «хезмәт (эш) урыны буенча» дигән сүзләр белән алыштырырга;

16 нчы пуктны түбәндәге редакциядә күрсәтергә:

«16. Бәйге комиссиясе составына министр һәм (яки) шуный ук вәкаләтле гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторыннан һәм граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләп торуга бәйге үткәрелә торган бүлекчәләрдән), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйге комиссиясе составына кертелүче бәйсез экспертлар – гражданлык хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә белгечләр булган, кадрлар технологияләре һәм гражданлык хезмәте мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә чакырыла торган фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Бәйсез экспертның бәйге комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш. Әлеге вакытны исәпләү бәйсез экспертның бәйге комиссиясе составына беренче кертелгән вакыттан гамәлгә ашырыла. Әлеге бәйсез экспертны бәйге комиссиясе составына кабат кертү бәйге комиссиясендә булу вакыты тәмамланганнан соң өч елдан соң гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары, бәйге комиссиясе составына кертү өчен, министр соравы буенча, әлеге Совет тарафыннан тәкъдим ителә.

Гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне кулланугa бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә бәйге үткәрү өчен бәйге комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Бәйге комиссиясе составы, бәйге комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп төзелә».

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының бәйге комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үзенең вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклап кала дип билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз артымда калдырам.

Министр В.А.Леонов